МИНИСТЕРСТВО КУЛЬТУРЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МӘДӘНИЯТ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

24.10.2017 г. Казань № 925 од

Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы карамагындагы Җәмәгать советы турында

2014 елның 21 июлендә имзаланган “Россия Федерациясендә җәмәгать контроле нигезләре турында”гы 212-ФЗ Федераль законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 18 ноябрендә имзаланган “Татарстан Республикасы Министрлыгы, дәүләт комитеты, ведомствосы карамагындагы җәмәгать советы турында”гы 906нчы карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 елның 15 октябре, 856нчы, 2013 елның 24 октябре 793, 2014 елның 20 сентябре №669, 2015 елның 14 мае №341, 2015 елның 5 сентябре №643, 2015 елның 17 ноябре №862, 2017 елның 10 октябре №781нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне истә тотып) нигезендә

**БОЕРАМ:**

1. Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы карамагындагы Җәмәгать советы турындагы түбәндәге Нигезләмәне расларга.
2. Боерыкның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Министр А.М. Сибагатуллин

Татарстан Республикасы
Мәдәният министрлыгының
«24» октября 2017 № 925 од
боерыгы белән расланган

Татарстан Республикасы
Мәдәният министрлыгы карамагындагы Җәмәгать советы турындагы
Нигезләмә

## 1. ГОМУМИ НИГЕЗЛӘМӘЛӘР

1.1. Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы карамагындагы Җәмәгать Советы (моннан соң - Җәмәгать Советы) Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы (моннан соң – Министрлык) карамагындагы киңәшче орган булып тора һәм Татарстан Республикасында мәдәният өлкәсендә дәүләт сәясәтен формалаштыру һәм гамәлгә ашыру барышында гражданнар хокукларын һәм ирекләрен һәм иҗтимагый оешмалар һәм дәүләтнеке түгел коммерциячел булмаган башка оешмалар, гражданнарның сыйфатлы хезмәт күрсәтүгә, аның эффективлыгына һәм куркынычсызлыгына булган хокукларын хокукларын гамәлгә ашыруга, халыкка хезмәт күрсәтү өлкәсендә дәүләти контроль һәм күзәтү системасын камилләштерүгә бәйле мәсьәләләрне карый, шулай ук әлеге Нигезләмәдә каралган башка вәкаләтләрне башкара.

1.2. Җәмәгать Советы составы һәм әгъзалары саны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслანучы Татарстан Республикасы министрлыгы, дәүләт комитеты, ведомствосы карамагында Җәмәгать Советы оештыру Тәртибе нигезендә Министрлык боерыгы белән раслана.

1.3. Җәмәгать Советы үзенең эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясе, федераль конституцион законнар, федераль законнар, Россия Президенты указлары һәм күрсәтмәләре, Россия Федерациясе Хөкүмәте карарлары һәм күрсәтмәләре, Татарстан Республикасы Конституциясе, Татарстан Республикасы законнары, Татарстан Республикасы Президенты указлары һәм күрсәтмәләре, Татарстан Республикасы Хөкүмәте карарлары һәм күрсәтмәләре, шулай ук әлеге Нигезләмә белән җитәкчелек итә.

1.4. Җәмәгать Советы карарлары тәкъдим характерында кабул ителә.

1.5. Җәмәгать Советы эшчәнлеге иҗтимагый башлангычта гамәлгә ашырыла.

1.6. Җәмәгать Советы эшчәнлеге ирекле нигездә, ачыктан-ачык һәм партнерлык принципларында Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары таләпләренә туры китереп алып барыла.

1.7. Җәмәгать Советы үз эшен гражданлык җәмгыяте институтлары, дәүләт идарәсе һәм җирле үзидарә органнары, массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләренең үзара кызыксынучанлыгы нигезендә алып барыла.

## 2. ҖӘМӘГАТЬ СОВЕТЫНЫҢ МАКСАТЛАРЫ, БУРЫЧЛАРЫ ҺӘМ ВӘКАЛӘТЛӘРЕ

2.1. Җәмәгать Советының төп максатлары булып түбәндәгеләр тора:
гражданнарның ихтыяҗларын һәм мәнфәгатьләрен барлау, мәдәният өлкәсендә дәүләт сәясәтен формалаштыру һәм гамәлгә ашыру барышында гражданнар хокукларын һәм ирекләрен һәм иҗтимагый оешмалар һәм дәүләтнеке түгел коммерциячел булмаган башка оешмалар хокукларын һәм ирекләрен яклау;

иҗтимагый, профессиональ һәм иҗади оешмаларны эшчәнлекнең тиешле өлкәсенә кагылган мәсьәләләр буенча дәүләт сәясәтенең төп юнәлешләрен булдыруга җәлеп итү, Министрлык эшчәнлегенең хәбәрдарлык һәм ачыклык принципларын тормышка ашыру;

Татарстан Республикасында дәүләт (муниципаль) оешмалар тарафаннан дәүләт (муниципаль) хезмәт күрсәтүгә иҗтимагый контрольне көчәйтү, мәдәният өлкәсендә ачыклык, законлылык һәм профессиональлек принципларын үстерү.

2.2. Җәмәгать Советының бурычлары булып түбәндәгеләр тора::

мәдәният өлкәсендә дәүләт сәясәтен камилләштерү буенча тәкъдимнәр әзерләү;

мәдәният өлкәсенә кагылышлы норматив хокукый актлар проектларына иҗтимагый экспертиза үткәрү, шул исәптән Министрлык тарафыннан әзерләнгән дәүләт программалары проектларын тикшерү;

Министрлык карарларында иҗтимагый фикерне исәпкә алу механизмын камилләштерү;

Министрлык эшчәнлегенең төп юнәлешләре буенча җәмгыятьнең хәбәрдарлыгын тәэмин итү;

мәдәният өлкәсендәне оешмалар тарафыннан күрсәтелүче хезмәтнең сыйфатына бәйсез бәя бирүне (моннан соң – сыйфатка бәйсез бәя бирү) үткәрү;

2.3. Җәмәгать Советының максатлары һәм бурычлары аның эшчәнлеге нәтиҗәләренә бәйле рәвештә, шулай ук Россия Федерациясендәге икътисади, социаль һәм сәяси шартларны күзә тотып үзгәрергә һәм тулыланырга мөмкин.

2.4. Җәмәгать Советын сыйфатка бәйсез бәя бирүне гамәлгә ашыру өчен үзенә йөкләнгән бурычлар кысаларында:

сыйфатка бәйсез бәя бирү үткәрелергә тиешле оешмаларның исемлеген билгели;

әлеге оешма тарафыннан күрсәтелүче хезмәт сыйфаты турында мәгълүматны җыючы, гомумиләштерүче һәм анализлаучы оешма (моннан соң – оператор) өчен техник бирем өчен тәкъдимнәр формалаштыра, эшләрне, хезмәтне сатып алу документациясе проектларын, шулай ук Министрлык белән оператор арасындагы дәүләт конрактлары проектарын карауда катнаша;

кирәк очракларда мәдәният өлкәсендәге оешмалар хезмәтенә бәйсез бәя бирү критерийларын билгели (федераль кануннар тарафыннан билгеләнгән критерийларга өстәмә рәвештә);

иҗтимагый фикерне, социаль хезмәт күрсәтүче, шул исәптән социаль юнәлештәге коммерциячел булмаган оешмалар, һөнәри җәмәгатьчелек һәм башка экспертлар рейтингын барлау, гомумиләштерү һәм анализлау эшен оештыра;

Министрлыкка түбәндәгеләрне юллый:

хезмәт күрсәтү сыйфатына бәйсез бәя бирү нәтиҗәләре;
оешмалар эшчәнлеген яхшырту буенча тәкъдимнәр.

## 3. ҖӘМӘГАТЬ СОВЕТЫ СОСТАВЫ

3.1. Җәмәгать Советы составы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан расланучы Татарстан Республикасы министрлыгы, дәүләт комитеты, ведомствосы карамагында Җәмәгать Советы оештыру Тәртибе нигезендә формалаштырыла.

3.2. Җәмәгать Советы Министрлык тарафыннан Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы белән берлектә ирекле нигездә 22 кеше составында формалаша.

3.3. Министрлык Җәмәгать Советы составы расланганнан соң 30 көн дәвамында Җәмәгать Советының беренче утырышын оештыра, утырышта совет әгъзалары арасыннан Җәмәгать Советының рәисе һәм аның урынбасары сайлана. Карар Җәмәгать Советының тулы составыннан ачык тавыш бирү нәтиҗәсендә иң күп тавыш җыю юлы белән кабул ителә.

3.4. Җәмәгать Советы рәисен яки рәисе урынбасарын эшеннән азат итү мәсьәләсе Җәмәгать Советы тарафыннан министр мөрәҗәгате буенча, шулай ук Җәмәгать Советы рәисе яки рәисе урынбасарының шәхси гаризасы буенча яисә Җәмәгать Советы гомуми составының биштән береннән дә ким булмаган әгъзалары төркеме тәкъдименнән чыгып карала. Карар Җәмәгать Советының гомуми составынын иң күп тавыш бирүчеләр саныннан чыгып кабул ителә.

3.5. Җәмәгать Советы рәисе Җәмәгать Советы әгъзалары составвыннан Җәмәгать Советының җаваплы сәркатибен билгели.

3.6. Җәмәгать Советы әгъзаларының вәкаләтләре яңа составтагы Җәмәгать Советының беренче утырышыннан соң 3 ел дәвам итә.

3.7. Җәмәгать Советы әгъзасы вәкаләтләре түбәндәге очракларда Җәмәгать Советы рәисе тәкъдиме буенча Министрлык боерыгы нигезендә туктатыла:

әгъза Россия Федерациясенең җинаять-процессуаль кануннары нигезендә җинаять кылуда гаепләнсә;

ул административ кулга алу ысулы белән административ җаваплылыкка тартылса;

аның дәүләт идарәсенең канун чыгару (вәкиллекле) органы депутатлыгына кандидат итеп, җирле үзидарә органындагы эш урынына сайлану максатыннан теркәлүе, сәяси партиянең ышанычлы шәхесе яисә вәкаләтле вәкиллегенә кандидат буларак теркәлүе, шулай ук аның Россия Федерациясендә референдум үткәрү буенча инициатив төркем составын керүе очрагында.

3.8. Җәмәгать Советы әгъзасы вәкаләтләре түбәндәге очракларда туктатыла:

вәкаләтләр вакыты чыгу нәтиҗәсендә;

аның Җәмәгать Советы составыннан чыгу турындагы гаризасы буенча;

аның саулыгы халәте сәбәпле Җәмәгать Советы эшендә катнаша алмавы;

аңа мөнәсәбәттә судның гаепләү хөкеме кануни көч алу нәтиҗәсендә

аның суд карары буенча кануни нигездә хокукый сәләтсез яисә хәбәрсез юкка чыккан булып танылуы нәтиҗәсендә;

аның этика нормаларын тупас бозуы очрагында - утырышта катнашучы Җәмәгать Советы әгъзалары составы тарафыннан иң күп тавыш бирү нәтиҗәсендә Җәмәгать Советы карары буенча;

Җәмәгать Советы утырышлары эшендә җитди сәбәпләрсез системалы рәвештә (өч тапкырдан да артык) катнашмау очрагында;

Җәмәгать Советы рәисе яки аның урынбасары йөкләмәләрен җитди сәбәпләрсез системалы рәвештә (өч тапкырдан да артык) башкармау очрагында;

аның Россия Федерациясе дәүләт вазифасына, Россия Федерациясе дәүләт гражданлык хезмәтенә, Татарстан Республикасы яисә Россия Федерациясенең башка субъектлары дәүләт вазифасына, Республикасы яисә Россия Федерациясенең башка субъектлары дәүләт гражданлык хезмәтенә, мцниципаль вазифага яисә муниципаль хезмәткә билгеләнүе сәбәпле;

аның чит ил гражданлыгы алуы нәтиҗәсендә;

аның Россия Федерациясе гражданы булуыннан туктавы сәбәпле.

3.9. Җәмәгать Советы әгъзасы вәкаләтләре Җәмәгать Советы әгъзасының язма гаризасы яки Җәмәгать Советы рәисе яисә аның урынбасары тәкъдиме буенча, шулай ук әлеге Нигезләмәнең 3.8 пунктында каралган сәбәпләр ачыклану очрагында Министрлык боерыгы белән туктатыла.

Җәмәгать Советы әгъзасы әлеге Нигезләмәнең 3.8 пунктының дүртенче, бишенче, унынчы – уникенче абзацларында каралган очраклар барлыкка килү турында Җәмәгать Советының рәисенә яки аның урынбасарына хәбәр итергә тиеш.

## 4. ҖӘМӘГАТЬ СОВЕТЫ ӘГЪЗАЛАРЫНЫҢ ХОКУКЛАРЫ ҺӘМ БУРЫЧЛАРЫ

4.1. Җәмәгать Советы әгъзасы түбәндәге хокукларга ия:

Министрлык инициативасы белән үткәрелүче барлык чараларда (утырышлар, киңәшмәләр, «түгәрәк өстәлләр» һ.б.) катнашырга, федераль кануннар нигезендә дәүләт сере булып саналучы мәгълүматлар, шәхси мәгълүматлар, чикле рөхсәт белән файдаланылучы мәгълүматлар кулланыла торган чаралар искәрмә булып тора;

инициатив тәртиптә Җәмәгать Советына аналитик хатлар, докладлар һәм башка мәгълүмати-аналитик материаллар әзерләргә һәм юлларга;

Җәмәгать Советы рәисе аркылы Җәмәгать Советының эш планына һәм аның утырышларын үткәрү тәртибенә тәкъдимнәр кертергә;

Җәмәгать Советы утырышлары көн тәртибендәге мәсьәләләрне карауда катнашу өчен чакырылучы кандидатлар буенча тәкъдимнәр кертергә;

Җәмәгать Советы әгъзалыгыннан чыгырга.

4.2. Җәмәгать Советы әгъзасы түбәндәге бурычларга ия:

Җәмәгать Советы рәисе йөкләмәләрен үтәргә;

Җәмәгать Советы ның әлеге Нигезләмә тарафыннан каралган тәртибен белергә сакларга;

Җәмәгать Советы утырышларында шәхсән катнашырга;

Җәмәгать Советы тарафыннан куелган мәсьәләләрне хәл итү максатында оештырылган эксперт, эшлекле төркемнәр, комиссияләр һәм башка эшлекле органнар эшендә катнашырга.

## 5. ҖӘМӘГАТЬ СОВЕТЫНЫҢ ЭШ ТӘРТИБЕ

5.1. Җәмәгать Советы үзенең эшен Җәмәгать Советы рәисе тәкъдиме белән Җәмәгать Советы утырышларында расланган план һәм программалар нигезендә оештыра.

5.2. Җәмәгать Советы эшен планлаштыру Җәмәгать Советы әгъзалары, Җәмәгать Советы рәисе һәм Министрлык тәкъдимнәре нигезендә алып барыла.

5.3. Җәмәгать Советы утырышлары кимендә кварталга бер тапкыр үткәрелә. Җәмәгать Советы утырышларында кабул ителгән карарлар протокол буларак формалаштырыла.

Җәмәгать Советы утырышлары шулай ук Министрлык инициативасы белән Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 29 мартында расланган “Татарстан Республикасы башкарма идарә органнары тарафыннан эшләнгән, элеге башкарма органнар карамагындагы җәмәгать советлары утырышларында алдан каралмыйча кабул ителә алмаган норматив хокукый актлар һәм башка документлар составын раслау турындагы” Карары нигезендә Министрлык тарафыннан эшләнгән, башкарма органнар карамагындагы җәмәгать советлары утырышларында алдан каралмыйча кабул ителә алмаган норматив хокукый актлар һәм башка документлар исемлегендә каралган проектларга Җәмәгать Советы бәяләмәсен алу максатыннан үткәрелә.

5.4. Җәмәгать Советы утырышлары аларда Җәмәгать Советы әгъзаларының кимендә ичтән икесе катнашкан очракта хокукый санала. Җәмәгать Советы әгъзасы утырышта шәхсән катнашу мөмкинлеге булмаганда, көн тәртибенә кертелгән сораулар буенча тавыш бирү хокукын, Җәмәгать Советы рәисенә яки аның урынбасарына, яисә Җәмәгать Советының җаваплы сәркатибенә бу хакта алдан хәбәр итеп, язма рәвештә, факсимиль яисә электрон почта аша Җәмәгать Советының башка әгъзасына тапшыра ала. Җәмәгать Советы утырышында катнашучы әгъзалар санына үзләренең тавышларын Җәмәгать Советының башка әгъзаларына тапшыручылар да кертелә.

Җәмәгать Советында әлеге Нигезләмәнең 5,3 пунктының икенче абзацында урын алган норматив хокукый актлар проектлары (норматив хокукый актлар) аларны Министрлык Җәмәгать Советына юллаганнан соң 10 көн дәвамында карала. Шул ук вакытта Җәмәгать Советы бәяләмәсен раслау өчен тавыш бирү Җәмәгать Советы әгъзаларыннан читтән торып сорашу үткәрү һәм шул сорашуның нәтиҗәләрен протоколга кертү, протоколга Җәмәгать Советы рәисе тарафыннан, ул югында - Җәмәгать Советы рәисе урынбасары тарафыннан кул кую юлы белән үткәрелергә мөмкин. Мондый тавыш бирү документларны почта, телеграф, телетайп, телефон, электрон яисә юлланучы хәбәрләрнең дөреслеген һәм документаль раслануын тәэмин итә торган башка элемтә чаралары ярдәмендә үткәрелергә мөмкин.Читтән торып тавыш бирү үткәрелгән очракта Җәмәгать Советы урынбасарына, Җәмәгать Советының барлык әгъзаларына Җәмәгать Советы бәяләмәсе алынырга тиешле норматив хокукый акт проекты (норматив хокукый акт) тавыш бирү көненә кимендә җиде көн кала юлланыла. Җәмәгать Советы әгъзалары

кирәк очракта норматив хокукый акт проекты (норматив хокукый акт) буенча Министрлыктан өстәмә материаллар һәм мәгълүмат соратып ала алалар.

Җәмәгать Советы карарлары күпчелек тавыш бирү нәтиҗәсендә кабул ителә. Тавышлар саны тигез булган очракта Җәмәгать Советы рәисе тавышы хәлиткеч булып санала.

5.5. Җәмәгать Советы утырышларын Җәмәгать Советы рәисе, ә ул юклыгында - Җәмәгать Советы рәисе урынбасары үткәрә.

5.6. Җәмәгать Советы карарлары аңа йөкләнгән максатлар, бурычлар, вәкаләтләр нигезендә рекомендация характерына ия һәм Җәмәгать Советы утырышы протоколы рәвешендә яисә Җәмәгать Советы карары нигезендә башка ысул белән кызыксынган вәкилләр игътибарына юллана.

5.7. Җәмәгать Советы эшчәнлеге турындагы мәгълүмат "Интернет" мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә Министрлык сайтында "Татарстан Республикасы Мәдәният министрылыгы карамагындагы Җәмәгать Советы" битендә урнаштырыла.

5.8. Җәмәгать Советы рәисе:

Җәмәгать Советы эшчәнлеге белән гомуми җитәкчелек итә;

Җәмәгать Советы утырышларын алып бара;

Җәмәгать Советы әгъзалары тәкъдимнәре нигезендә Җәмәгать Советының эш планнарын әзерли, шулай ук аларга үзгәрешләр кертә һәм аларны Җәмәгать Советы раславына тәкъдим итә.

Җәмәгать Советы утырышларын оештыра;

Җәмәгать Советы утырышларының көн тәртибен раслый;

Җәмәгать Советы рекомендацияләрен, протоколларын һәм Җәмәгать Советының башка документларын имзалый;

Җәмәгать Советы утырышларының үткәрелү вакытын һәм урынын билгели;

Җәмәгать Советы эшчәнлеге, аңа йөкләнгән максатлар һәм бурычлар кысаларында Җәмәгать Советы әгъзаларына йөкләмәләр бирә

Җәмәгать Советы исеменнән юллanучы запрослар, рекомендацияләр, тәкъдимнәр, җаваплар, аңлатмалар һәм мөрәҗәгатьләрне имзалый;

Җәмәгать Советы эшчәнлеген тәэмин итү өчен кирәкле башка функцияләрне үти.

5.9. Җәмәгать Советы рәисе урынбасары:

Җәмәгать Советы рәисе булмаган очракта аның функцияләрен үти;

Җәмәгать Советы утырышларын әзерләүне оештыра;

Җәмәгать Советы утырышларының көн тәртибен төзи һәм аны Җәмәгать Советы рәисе раславына тәкъдим итә;

Җәмәгать Советы рәисе кушуы буенча Җәмәгать Советы эшчәнлеген тәэмин итү өчен башка функцияләрне үти.

5.10. Җәмәгать Советының җаваплы сәркатибе:

Утырышларга материалар һәм карарлар проектларын әзерләүне оештыра;

Җәмәгать Советы әгъзаларына Җәмәгать Советы утырышы үткәрелү урыны һәм вакыты, аның көн тәртибе турында хәбәр итә, аларны кирәкле мәгълүмати-белешмә материаллар белән тәэмин итә;

Җәмәгать Советы һәм Министрлыкның оештыру мәсьәләләре буенча бәйләнешен тәэмин итә;
Җәмәгать Советы эшчәнлегенең документаль-техник тәэмин ителешен оештыра;
Җәмәгать Советы утырышларының протоколларын формалаштыра һәм кабул ителгән карарларның үтәлешен контрольдә тота;
Җәмәгать Советы утырышларының көн тәртибен төзүдә катнаша.

5.11. Җәмәгать Советы әгъзалары Җәмәгать Советы утырышларында тыңлалачак һәм каралачак мәсьәләләрне әзерләү максатында эшлекле, эксперт һәм башка эш органнарын берләшергә, Җәмәгать Советы урынбасары белән килешү нигезендә материаллар әзерләүгә Җәмәгать Советы составына кермәгән башка белгечләрне җәлеп итәргә мөмкин.

5.12. Җәмәгать Советы карары буенча Җәмәгать Советы утырышларына Җәмәгать Советы тарафыннан карала торган мәсьәләләр буенча тиешле белешмәләр һәм бәяләмәләр бирү өчен башкарма органнар, комерциячел булмаган оешмалар, фәнни учреждениләр вәкилләре, экспертлар һәм башка белгечләр чакырылырга мөмкин. Массакүләм мәгълүмат чараларының Җәмәгать Советы әгъзасы булмаган вәкилләре Җәмәгать Советы утырышларында Җәмәгать Советы чакыруы буенча катнаша алалар.

5.13. Җәмәгать Советы үз эшендә Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы әгъзалары катнашуын тәэмин итә.

5.14. Җәмәгать Советы карамагына кертелүче материаллар алар каралырга тиешле Җәмәгать Советы утырышы билгеләнгән көнгә кимендә ун көн кала Җәмәгать Советы рәисе урынбасарына тапшырылырга тиеш. Материалларны соңарып тапшыру очраклары Җәмәгать Советы рәисе яисә аның урынбасары белән килешенә.

5.15. Җәмәгать Советының оештыру-техник яктан эшчәнлеген Министрлык тәэмин итә.